# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Каенлык авыл җирлеге Тимофеевка торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

№ 26 05 ноябрь 2024 ел

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында”, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында”, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законының 35 статьясы нигезендә, 2024 елның 2 ноябрендә уздырылган “Сез 2025 елда Каенлык авыл җирлеге территориясендә Тимофеевка торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә, һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрү белән килешәсезме:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (юлларны кышкы тоту: ягулык-майлау материаллары сатып алу, кар чистарту, тракторчының хезмәт хакы)»

«РИЗА» «КАРШЫ».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 9 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 7 кеше, бу 77,7 %ны тәшкил итә.

тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар түбәндәгечә бүленде:

“Риза” позициясе өчен гражданнар җыенында 7 катнашучы тавыш бирде; “Каршы” позициясе өчен җыенда катнашучы 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, гражданнар җыены түбәндәгечә хәл итте:

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Каенлык авыл җирлеге Тимофеевка торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. “Сез 2025 елда Тимофеевка авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә, һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?” дигән мәсьәлә буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча беркетмә төзелде:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (юлларны кышкы тоту: ягулык-майлау материаллары сатып алу, кар чистарту, тракторчының хезмәт хакы)»

«РИЗА» «КАРШЫ» -кабул ителгән.

3. Әлеге карарны мәгълүмати стендларда, Биектау муниципаль районы рәсми сайтында авыл җирлекләре бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлар регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Каенлык авыл җирлеге башлыгы А.Ә.Әминов